ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы эшчәнлеге турында мәгълүмат хакында

Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесе В.В. Виниченконың Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы эшчәнлеге турындагы мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы эшчәнлеге турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Медицина эшчәнлегенең сыйфатын һәм иминлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне), дарулар әйләнешен дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне), медицина әйберләре әйләнешен дәүләт тарафыннан тикшереп торуны гамәлгә ашырганда вәкаләтләрне башкару кысаларында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә, шул исәптән гражданнарның хокукларын үтәү өлешендә, тикшереп тору системасын камилләштерү эшен дәвам итәргә.

2.2. «Озак һәм актив яшәү», «Гаилә» илкүләм проектлары чараларын башкаруны тикшереп торуны республика башкарма хакимият органнары белән хезмәттәшлектә гамәлгә ашырырга.

2.3. Тикшереп торуның дистанцион рәвешләрен, шул исәптән «Инспектор» мобиль кушымтасыннан файдаланып, үстерүне дәвам итәргә.

2.4. Лицензиясез эшләү фактларын ачыклау максатларында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла торган медицина хезмәт күрсәтүләре турындагы мәгълүматны мониторинглауны дәвам итәргә.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. «Медицина эшчәнлегенең сыйфаты һәм иминлеге» медицина оешмаларын ихтыярый сертификацияләү системасы кысаларында медицина оешмалары эшчәнлеген Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең стандартлары таләпләренә туры китерү өлешендә эшне активлаштырырга.

3.2. Ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларында Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы тарафыннан контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәсендә ачыклана торган хокук бозуларга юл куймау чараларын күрергә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитетына сәламәтлек саклау өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен дәвам итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 27 ноябре
№ 468-VII ДС